РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 сентябрь 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

2022 елның 08 октябрендә 13 сәг.00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 08 октябрендә-13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Карамалы-Елга авылы, Сәйдәшев ур., 39, Карамалы-Елга авылы мәчете бинасы;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2022 елның 27 сентябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Туйкә авылы, Җәлил урамы, 19 йорт, Карамалы-Елга авылы, Сәйдәшев ур. 39 ;

- сайлау хокукына ия Карамалы-Елга торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Карамалы-Елга торак пунктына халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

1. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өчен: 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәкләр, күп балалы гаиләләр өчен түләүне бер тапкыр киметеп 500 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы

- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру ( эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү) килешү буенча эшләр өчен түләү

- Карамалы-Елга авылында авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү ,чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре өчен түләү );

- Карамалы-Елга авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Авылга 100ел бәйрәме», нә бүләк, сувенир продукция сатып алу);

- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру ( эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү) килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Карамалы-Елга авылында күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар алу, контейнер мәйданчыгы урнаштыру, контейнерлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, һәм түбәндәге адреслар җуенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлили ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга авылында., Сәйдәшев ур. 39;

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам..

Башлык Р.Р.Закирова